**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-12-91

**2022елның «07» июляе** **13/1-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең уңай яшәү шартларына, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә;

2. Ачык тыңлаулар үткәрү чорын - кызыксынган затларга аларны үткәрү турында хәбәр итү вакытыннан гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр дип билгеләргә. Ачык тыңлауларны үткәрү вакыты бер айдан да ким өч айдан артык булмаска тиеш;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган Иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамә әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән 14 эш көне эчендә әлеге карарның 3.1.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чорда ачык тыңлаулар үткәрергә;

3.4. Ачык тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Генераль планы проектын, ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына ахыргы карар кабул итү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)..

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы В.В. Михеевка йөкләнә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**

**вазыйфаларын башкаручы** **И.Ю. Романова**